ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**24 декабрь 2021 ел** **№ 22**

**«Иске Чүриле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым акчаларын
җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 12 ноябрь 2021 г. №1, 12 ноябрь 2021 г. №2, 12 ноябрь 2021 г. №3, 15 ноябрь 2021 г. №4, 15 ноябрь 2021 г. №5, 16 ноябрь 2021 г. №6, 20 ноябрь 2021 г. №7, 23 ноябрь 2021 г. №8 җыеннарда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 31 номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт; Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомольская урамы, 4А йорты; Арча районы, Штерә авылы, Советская урамы, 30б йорты; Арча районы, Венета авылы, Центральная урамы, 13 йорт.
3. «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Иске Чүриле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 22 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл
җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин

Иске Чүриле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.12.2021 ел, № 22
карарына 1 нче кушымта

**«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 23 февраленә кадәр «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.12.2021 ел, №22 карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________________________
Адресы:________________________________________________________________
_____________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр _________ сум күләмендә
___________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № _______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН __________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
_________________________________________________________________________бер
тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ _______________________________________

М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: ______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел ____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*